ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ШУШМАБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.1б, с.Шушмабаш,
Арский муниципальный район,422036

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ШУШМАБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Мәктәп урамы, 1б йорт, Шушмабаш авылы,
Арча муниципаль районы,422036

Тел. (84366) 93-1-24 факс (84366) 93-1-24. E-mail: Shush.Ars@tatar.ru

# КАРАР

**14 август 2020 ел** **№21**

**Шушмабаш авыл җирлеге башкарма комитетының 2016 елның 27 декабрендәге "Муниципаль мәгълүмат системаларының эшләү һәм алардан файдалану тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында" 51 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында (22.08.2019 ел, №124 үзгәрешләр белән)**

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 27 декабрендәге 1906 номерлы РФ Хөкүмәте карары кабул ителүгә бәйле рәвештә, "Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны яклау турында" 2006 елның 27 июлендәге 149-ФЗ номерлы Федераль законга, "Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында" 2013 елның 5 апрелендәге "Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында" 44-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясына, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 28 ноябрендәге "Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алу өлкәсендә төбәк һәм муниципаль мәгълүмат системаларына Бердәм таләпләр турында" 1091 номерлы карарына туры китерү максатыннан, Шушмабаш авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Шушмабаш авыл җирлеге башкарма комитетының 2016 елның 27 декабрендә кабул ителгән "Муниципаль мәгълүмат системаларының эшләү һәм алардан файдалану тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында” 51 номерлы карары (22.08.2019ел,№124 үзгәрешләр белән) белән расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы "Шушмабаш авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең муниципаль мәгълүмат системалары эшчәнлеге һәм алардан файдалану тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.7. Сатып алулар өлкәсендә контракт системасын мәгълүмати тәэмин итү максатыннан авыл җирлеге башкарма комитеты Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән сатып алулар өлкәсендә региональ һәм муниципаль мәгълүмат системаларына бердәм таләпләр нигезендә бердәм мәгълүмат системасы белән интеграцияләнгән муниципаль мәгълүмат системасын булдырырга хокуклы.

Әлеге система түбәндәгеләрне тәэмин итәргә тиеш:

1) контракт системасы турында Федераль законның 1 статьясындагы 1 өлешендә күрсәтелгән мөнәсәбәтләр кысаларында сатып алулар өлкәсендә контракт системасында катнашучыларга мәгълүматлар формалаштыру, эшкәртү, саклау һәм бирү (шул исәптән автоматлаштырылган);

2) сатып алуларның идентификация кодлары турындагы мәгълүматның туры килүен һәм әлеге сатып алуларны гамәлгә ашыру өчен финанс ягыннан тәэмин итү күләмен арттыруны контрольдә тоту:

- сатып алуларны тормышка ашыру турында хәбәрнамәләрдә, план-графикларда булган мәгълүматларда;

- сатып алуларны тормышка ашыру турында хәбәрнамәләрдә булган мәгълүмат белән тәэмин итүчеләрне (подрядчыларны, башкаручыларны) билгеләү беркетмәләрендә;

-"Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында" Федераль закон нигезендә, контрактлар төзелә торган сатып алуларда катнашучыларга бердәм мәгълүмат системасын кулланып җибәрелә торган контрактлар проектлары шартларында - тәэминатчыларны (подрядчыларны, башкаручыларны) билгеләү беркетмәләрендә булган мәгълүматларда;

3) контракт системасы турында Федераль законда каралган электрон документларга кул кую өчен Федераль законда каралган электрон имза төрен (алга таба - электрон имза) куллану.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтында "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://arsk.tatarstan.ru.

3. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Шушмабаш авыл җирлеге башлыгы В.В.Сәгыйтов

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ШУШМАБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ